СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЫЖМАРА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«13» март 2023 ел № 67

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 237-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Пыжмара авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының 22.04.2021 ел, № 22 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 23 статьяның 3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге пунктчалар белән тулыландырылырга:

"4) нормалаштырылмаган хезмәт көне өчен айлык өстәмә;

5) закон нигезендә муниципаль хезмәткәрнең акчалата тотышын тәшкил итүче башка өстәмә түләүләр, алар эш бирүченең аерым боерыгы белән билгеләнә».

1.2.31 нче маддәнең 4 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт үткән чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат Формалаштыру һәм күрсәтелгән мәгълүматларны Россия Федерациясе мәҗбүри пенсия иминияте һәм мәҗбүри социаль иминият системаларында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәп-хисап турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә пенсия һәм Россия Федерациясенең социаль иминиятләштерүе;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль

районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Башкаруны контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Пыжмара авыл
җирлеге башлыгы Р.Х.Җәләев